«Раслыйм»
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

___________Р.А. Ильясов

«Килешенде»
Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль
районы Башкарма комитеты
МКУ «Мәгариф идарәсе» башлыгы
______________Р.М. Шакирова

**«Татар сөлгесе – күңел көзгесе»**
**район бәйгесе үткәрү турында нигезләмә**

*Бәйрәмнәрдә затлы бизәк булып,*
*Балкыган ул өйнең түрендә.*
*Көрәшкәндә, көч-дәрт биреп торган*
*Мәйданнарда батыр билендә.*

*Уңган киленкәйнең күңеле дә*
*Бүз сөлгелек кебек булган ак.*
*Бизәк чиккән сайлап, юансын дип,*
*Чабышларда соңгы килгән ат.*

*Чиккән сөлге икмәк-тозлы булган*
*Яшь кәләшне каршы алганда.*
*Гаилә ядкаренә әйләнгән ул,*
*Сандыкларга төреп салганда.*

*Кызыл башлы, чуптар-чүпләмле шул,*
*Чиккән сөлге – вәгъдә билгесе.*
*Тоныкланмас җете бизәкләре,*
*Ул – халкымның күңел көзгесе.*

**Татар халкының милли мәдәни мирасын саклау һәм баету, борынгыдан килгән гореф-гадәтләрне киңрәк өйрәнү, педагогларның иҗади сәләтләрен барлау һәм тәҗрибә уртаклашу максатлары белән «Татар сөлгесе - күңел көзгесе» район бәйгесе игълан ителә.**

**Бәйгедә катнашалар: укытучылар, тәрбиячеләр, өстәмә белем бирү педагоглары.**

**Бәйгегә җирлегебездә сакланып килгән милли бизәкләр, үрнәкләр нигезендә чигелгән *2 м х 50 см* зурлыкта татар халкының милли сөлгеләре кабул ителә. Чигү ысуллары чикләнмәгән.**

**Сөлгеләр 2024 елның 19 мартына кадәр Балалар иҗат үзәгендә кабул ителә (Актаныш авылы, Юбилей урамы, 111). Бәйге эшенең авторның исем, фамилиясе, белем бирү оешмасы күрсәтелгән ярлыгы булу шарт.**

**Гаризалар (заявкалар) 2024 елның 19 мартына кадәр konkurs.iu@mail.ru электрон почтасына кабул ителә. (темага “Татар сөлгесе. ФИО, белем бирү оешмасы”)**

**Бәйгене йомгаклау:**

**Бәйгегә килгән иҗат эшләреннән күргәзмә оештырыла.**

**Җиңүчеләр һәм призерлар билгеләнә, дипломнар һәм сертификатлар белән бүләкләнә.**

**«Татар сөлгесе - күңел көзгесе»**
**район бәйгеседә катнашу өчен заявка**

| Белем бирү оешмасы | Катнашучыларның исем, фамилиясе, атасының исеме | бәйге эшенең тасвирламасы яки фотосы | e-mail, телефон |
|---|---|---|---|
| | | | |